**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 2 апреленнән № 26

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
«Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү буенча карар проекты турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советы,

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 25 маендагы 79 номерлы Ижевка авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Шәһәр төзелеше регламентлары. Торак зоналары.» 35 статьяның «Шәһәр төзелеше зонасы картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв.м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану рәвешендәге җир кишәрлекләренең максималь күләме - 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советы Карары проектын карау буенча 2021 елның 24 маенда 11 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча ачык тыңлаулар үткәрергә: Татарстан

Республикасы, Ижевка авыл җирлеге, Ижевка авылы, Совет ур., 26 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге мәдәният йортының актлар залы.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

4. Комиссиягә югарыда күрсәтелгән проектның демонстратив материаллары экспозициясен «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советы карары проекты белән таныштырырга, кызыксынган затларның искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Ижевка авыл җирлеге, Ижевка авылы, Совет ур., 26 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге мәдәният йортының актлар залы.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ «Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Ижевка авыл җирлеге Советы рәисе Н.М.Сергеева

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге
Советының
2021 елның 2 апреленнән
26 нчы номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Ижевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча комиссия составы

1. Рәис: Сергеева Нина Михайловна - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге башлыгы;
2. Рәис урынбасары: Вәлиев Рәмис Мирсәет улы - Ижевка авыл җирлеге Советы депутаты;
3. Секретарь: Нургалиева Фәнисә Шәмсимөхәммәт кызы - Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре;
4. Комиссия әгъзасы: Сабирова Лилия Илдус кызы – Ижевка авыл җирлеге Советы депутаты;
5. Комиссия әгъзасы: Веклич Ксения Андреевна – Ижевка авыл җирлеге Советы депутаты;
6. Комиссия әгъзасы: Хәбиров Равил Зөфәр улы – Менделеевск муниципаль районы инвестицион һәм инфраструктура үсеше идарәсенең проектлау бүлеге башлыгы.